**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2019 елның «13» маеннан № 34

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының 2008 елның 7 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган «Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш Тәртибен раслау турында» гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш Тәртибенә өстәмәләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм миграция өлкәсендә һәм эчке эшләр өлкәсендә дәүләт идарәсен үзгәртеп коруга бәйле рәвештә «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» Федераль законның 22 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 528 – ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, **карар бирәм**:

1. гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш Тәртибенең 1 номерлы «Гомуми нигезләмәләр» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 1.14 пункт өстәргә:

«Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу фактлары ихтимал булуы турында мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать, теркәлгәннән соң биш көн эчендә, мөрәҗәгать җибәргән гражданинга, аның мөрәҗәгатенең башка адрес буенча җибәрелүе турында хәбәрнамә белән Эчке

эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органына җибәрелә. Искәрмә: «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан башка очракларда.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына 2018 елның 27 декабрендәге 528-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм миграция өлкәсендә һәм эчке эшләр өлкәсендә дәүләт идарәсен үзгәртеп коруга бәйле рәвештә «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» Федераль законның 22 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә норматив хокукый актлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» https://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырырга (халыкка игълан итергә);

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башлыгы** **В.М. Козлов**